КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 август г.Казань № 733

Яшьләр өчен социаль әһәмиятле проектларны тормышка ашыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Яшьләр өчен социаль әһәмиятле проектларны тормышка ашыруга коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен расларга.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында студент-ларның хезмәт отрядларына булышлык күрсәтүгә һәм аларны үстерүгә юнәлтелгән социаль әһәмияттәге проектларны тормышка ашыра торган коммерциячел булмаган оешмаларга грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 20 май, 330 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны һәм программаларны тормышка ашыру өчен грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 6 август, 539 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 20 ноябрь, 1024 нче карарының 1 һәм 3 пунктлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларының аерым нормалары гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2020 ел,  18 июнь, 498 нче карарының 3 һәм 4 пунктлары.

3. 3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А. В. Песошин